КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 сентябрь г.Казань № 836

«Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне һәм «Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучыларның үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карарын тормышка ашыру максатларында, шулай ук җәмгыятьнең Татарстан Республикасы Архив фонды документларындагы һәм башка архив документларындагы мәгълүматны алуга булган агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм дәүләт идарәсе системасын документлар белән тәэмин итү нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә);

«Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучыларның үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын (алга таба – Регламент).

2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетын «Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба — дәүләт мәгълүмат системасы) заказчысы һәм операторы итеп билгеләргә.

3. Дәүләт мәгълүмат системасын эксплуатацияләүгә һәм үстерүгә (модернизацияләүгә) бәйле эшләрне финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карары белән расланган «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыруга күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлегендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалануны һәм Нигезләмәгә һәм Регламентка таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин